КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 ноябрь г.Казань № 1477

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясендә региональ үсеш буенча хөкүмәт комиссиясе президиумының (штабының) 2023 елның 29 июнендәге 35 номерлы беркетмәсе белән расланган гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы махсус казначылык кредитлары булган гомуми файдаланудагы пассажир транспортының күчмә составын сатып алу чараларының детальләштерелгән исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджетның бердәм счетының вакытлыча файдаланылмаган акчасы исәбеннән бюджет кредитлары бирү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясендә региональ үсеш буенча хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәнең $12^1$ пунктына үзгәреш кертү хакында» 2023 елның 31 мартындагы 525 нче карары белән расланган Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджетның бердәм счетының вакытлыча файдаланылмаган акчасы исәбеннән бюджет кредитлары бирү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясендә региональ үсеш буенча хөкүмәт комиссиясе президиумының (штабының) 2023 елның 29 июнендәге 35 номерлы беркетмәсе белән расланган гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы махсус казначылык кредитлары булган гомуми файдаланудагы пассажир транспортының күчмә составын

сатып алу чараларының детальләштерелгән исемлеген (алга таба шул ук эзлеклелектә – чаралар, детальләштерелгән исемлек) расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

детальләштерелгән исемлек нигезендә чараларны гамәлгә ашыруны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20есенә кадәр, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы билгеләгән форма буенча, шулай ук  дәүләт мәгълүмат системаларын файдаланып электрон рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына чараларны гамәлгә ашыру турында белешмәләр кертүне;

чараларны гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы рәсми соравы буенча документлар, материаллар һәм мәгълүмат тапшыруны;

бу карарны, аңа кертелә торган үзгәрешләрне Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгына һәм Федераль казначылыкка җибәрүне.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына махсус казначылык кредиты буенча бурычларны тулысынча каплаганга кадәр квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр Федераль казначылык тарафыннан билгеләнә торган форма буенча махсус казначылык кредиты акчасын Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрү турында хисап әзерләү өчен белешмәләр бирүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр, түбәндәгеләрне кертүне тәэмин итәргә:

чараларны гамәлгә ашыру турындагы белешмәләрне Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгына;

махсус казначылык кредиты буенча бурычларны тулысынча каплаганга кадәр Федераль казначылык тарафыннан билгеләнә торган форма буенча махсус казначылык кредиты акчасын Федераль казначылыкка җибәрү турындагы хисапны.

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

чараларны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы арасында төзелгән Татарстан Республикасы территориясендә чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы махсус казначылык кредитлары булган гомуми файдаланудагы пассажир транспортының күчмә составын сатып алу чараларын гамәлгә ашыру турындагы 2023 елның 23 августындагы 12-137/С номерлы килешү нигезендә башкарыла;

финанс белән тәэмин итү чыганагы махсус казначылык кредиты акчасы булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 13 ноябрь, 1477 нче
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясендә региональ үсеш буенча хөкүмәт комиссиясе президиумының (штабының) 2023 елның 29 июнендәге 35 номерлы беркетмәсе белән расланган гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы махсус казначылык кредитлары булган гомуми файдаланудагы пассажир транспортының күчмә составын сатып алу чараларының детальләштерелгән исемлеге

| Т/с | Чараның исеме | Маршрутлар саны | Класслар буенча автобуслар саны, берәмлек | | | Маркасы һәм моделе | Барысы | Финанслау чыганаклары | | | Транспорт чараларын кадәр кайтарту сроклары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | олы | уртача | кече | | | махсус казначылык кредиты | берләштерелгән төбәк бюджеты акчасы | бюджеттан тыш чыганаклар | |
| | | | | | | | мең сум | мең сум | мең сум | мең сум | кк.аа.ееее |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | Барлыгы | 44 | 76 | 30 | 15 | | 1 396 106,40 | 1 396 106,40 | 0,00 | 0,00 | Х |
| | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен гомуми файдаланудагы пассажир транспортының күчмә составын сатып алу, барысы, шул исәптән: | 44 | 76 | 30 | 15 | | 1 396 106,40 | 1 396 106,40 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 1. | Азнакай шәһәре | 2 | - | 3 | - | ПАЗ 320405-14 NEXT 7.6 | 22 938,00 | 22 938,00 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 2. | Әлмәт шәһәре | 3 | 9 | - | - | НЕФАЗ 5299-0000040-57 | 136 398,60 | 136 398,60 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 3. | Баулы шәһәре | 1 | - | - | 1 | ГАЗель А68R52 | 4 106,60 | 4 106,60 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 4. | Бөгелмә шәһәре | 4 | - | 14 | - | ПАЗ 320405-14 NEXT 7.6 | 107 044,00 | 107 044,00 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Алабуга шәһәре | 6 | - | - | 6 | ГАЗель A65R52 | 23 430,00 | 23 430,00 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 6. | Зәй шәһәре | 2 | - | 5 | - | ПАЗ 320405-14 NEXT 7.6 | 38 230,00 | 38 230,00 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 7. | Зеленодольск шәһәре | 1 | 10 | - | - | LOTUS 105 C-02 | 129 900,00 | 129 900,00 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 8. | Лениногорск шәһәре | 10 | - | 7 | 7 | ПАЗ 320405-14 NEXT 7.6, ГАЗель A68R52 | 82 268,20 | 82 268,20 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 9. | Түбән Кама шәһәре | 9 | 11 | - | - | LOTUS 105 C-02 | 142 890,00 | 142 890,00 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 10. | Нурлат шәһәре | 1 | - | - | 1 | ГАЗель A68R52 | 4 106,60 | 4 106,60 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 11. | Минзәлә шәһәре | 1 | - | 1 | - | ПАЗ 320405-14 NEXT 7.6 | 7 646,00 | 7 646,00 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |
| 12. | Яр Чаллы шәһәре | 4 | 46 | - | - | НЕФАЗ 5299-0000040-57 | 697 148,40 | 697 148,40 | 0,00 | 0,00 | 01.02.2024 |